**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы**
**КАРАРЫ**

Актүбә ш.т.б. № 18 «18» сентябрь 2017 ел

Референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында», Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә » муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән,

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының**
**Азнакай шәһәр тибындагы бистә Советы карар кабул итте:**

«Сез 2018 елда Актүбә шәһәр тибындагы бистә " муниципаль берәмлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:

1. янгын гидрантларын сатып алу;
2. каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнерлар сатып алу;
3. өстәмә урам яктырткычларын сатып алу һәм монтажлау;
4. яңа мөселман һәм христиан зиратларын төзекләндерү (контейнерлар куела торган контейнер мәйданчыкларын төзекләндерү, су өчен савытлар сатып алу һәм урнаштыру, керү юлларын, машина кую урыннарын төзекләндерү, квартал эчендәге юлларны төзекләндерү, яңа христиан зираты өчен инвентарь будкасы, ритуаль бүлмә төзү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карар;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Актүбә шәһәр тибындагы бистә» муниципаль берәмлегенең түбәндәге адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында: ТР, Азнакай районы, пгт.Актүбә ш.т.б.., Губкин ур., 24;
- Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча :http://pravo.tatarstan.ru;
- «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында: http://aznakaevo.tatarstan.ru. урнаштыру ярдәмендә игълан ителә.

Рәис Р.А. Галиева